**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

г.Казань

10.10.2017 № 01-02/117

Татарстан Республикасы юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс турында» 112 номерлы Указы нигезендә һәм Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2017 елның 1 мартында 96 номерлы Указ белән расланган Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турындагы нигезләмә” нигезендә, боерам:

Татарстан Республикасы юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турындагы Татарстан Республикасы юстиция министры тарафыннан 2016 елның 11 ноябрендә расланган 01-02/288 номерлы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы юстиция министры» сүзләрен «Татарстан Республикасы юстиция министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат)» сүзләренә алыштырырга;

3.2 пунктта «граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына» сүзләрен «граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә» сүзләренә алыштырырга;

3.4 пунктның өченче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган формада тутырылган һәм имза куелган, фотосурәт беркетелгән анкетасын;»;

3.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Бүтән дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашуга теләк белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә гаризасын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган формада тутырган һәм имзаланган, үзе граждан хезмәте вазыйфасын башкара торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан расланган, фотосурәт беркетелгән анкетасын тапшыра.»;

3.6 пунктның икенче абзацына түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«Электрон рәвештә бирелгән мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерүгә юлланалар.»;

3.7 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында алар кабул ителү турында хәбәр урнаштырылганнан соңгы 21 көн эчендә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан дәүләт органына шәхсән, почта аша юллау яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат системасыннан файдаланып электрон рәвештә тапшырылалар.

Документларның нигезсез сәбәпләр аркасында үз вакытында тапшырылмавы, тулы күләмдә тапшырылмавы яки тутыру кагыйдәләрен бозып тапшырылуы гражданинның (граждан хезмәткәренең) документларын алудан баш тарту өчен нигез булып тора.

Документларның нигезле сәбәпләр аркасында үз вакытында тапшырылмавы, тулы күләмдә тапшырылмавы яки тутыру кагыйдәләрен бозып тапшырылуы очрагында министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.»;

3.8 пунктны үз көчен югалткан дип санарга;

4.4.2 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданинның граждан хезмәтенә керүенә каршылык тудыра торган сәбәпләр чыккан очракта, ул министр тарафыннан конкурста катнашуга кертелмәү сәбәпләре турында язма рәвештә искәртелә. Гражданин конкурста катнашуга документларын электрон рәвештә җибәргән очракта конкурста катнашуга кертелмәү сәбәпләре турындагы белдерү аңа дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән булган электрон документ рәвешендә җибәрелә.»;

4.4.5 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач министр конкурсның икенче этабын уздыру вакыты, урыны һәм көне турында (катнашу өчен документлар кабул ителү төгәлләнгәннән соңгы көннән 30 календарь көннән дә соңрак түгел) карар кабул итә. Дәүләт сере яки закон тарафыннан саклана торган башка сер булып торучы мәгълүматларны алуга рөхсәт рәсмиләштерү очрагында конкурсның икенче этабын уздыру вакытын министр билгели.

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга 15 көннән дә соңга калмыйча Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында конкурс үткәрелү датасы, урыны һәм вакыты, конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар исемлеге турында хәбәр урнаштыра һәм әлеге мәгълүматны кандидатларга язма рәвештә юллый. Конкурста катнашуга документларын электрон рәвештә юллаган кандидатларга – күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән булган электрон документ рәвешендә җибәрә.»;

4.4.8 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«4.4.8. Министрлыкта дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва итүче кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган тестлаштыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4.9 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«4.9. Конкурс нәтиҗәләре турында белдерү конкурс тәмамланганнан соңгы 7 көн эчендә кандидатларга язма рәвештә, ә конкурста катнашуга гаризаларын электрон рәвештә җибәргән кандидатларга – дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән булган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат шушы ук вакыт эчендә Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге күрсәтелгән мәгълүмат системасында урнаштырыла;»;

4.11 пунктка түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«Конкурста катнашуга электрон рәвештә килгән гаризалар өч ел дәвамында саклана, бу вакыт узганнан соң алар юкка чыгарыла.».

Министр Р.И. Заһидуллин